ГЛАВА
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.02.2019 п.г.т. Алексеевское №13

**“Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә
оешмаларның хезмәтләр күрсәтү
шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү буенча
җәмәгать Советы турындагы
Нигезләмәне раслау хакында”
Алексеевск муниципаль районы башлыгының
28 август, 2018 ел, 85 нче карарына үзгәрешләр
кертү хакында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән “Җәмәгать контроле нигезләре турында”гы 21 июль, 2014 ел, 212-ФЗ санлы Федераль законга туры китерү максатында

**карар бирәм:**

1. “Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмаларның хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү буенча җәмәгать Советы турындагы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башлыгының 28 август, 2018 ел, 85 нче карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9. Мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмаларның хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү буенча җәмәгать Советы составына Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хезмәте вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче, шулай ук “Россия Федерациясе Җәмәгать палатасы турында”гы 4 апрель, 2005 ел, 32-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Җәмәгать палатасы әгъзалары була алмаган затлар керә алмыйлар.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый

мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Н.П. Чуринга йөкләргә.

**Муниципаль район башлыгы** **С.А.Демидов**